**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Карата авыл**
**җирлеге**
**башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Старохурадинского**
**сельского поселения**
**Алькеевского муниципального**
**района РТ**

Адрес: 422898, РТ, Әлки районы Сиктәрмә
авылы, Мәктеп ур., 15й Тел/факс: (84346) 73-4-03

Адрес: 422898, РТ, Алькеевский район с. Сиктерме
Школьная, д.15 тел/факс: ( 84346) 73-4-03

# КАРАР

2025 елның 09 июне № 39

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Каратаавыл җирлегеБашкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күплэп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Сиктерме авылы Мәктәп урамы буенча (авыл җирлеге бинасы белән клуб-музей арасында),
- Иске Хурада авылы (мәктәп һәм Елга урамнары арасында)

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Карата авылҗирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
Вазыйфаларынбашкаручы Е.В.Казанкова